**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның «3» июне № 55-166

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86-88 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 10.03.2015 ел, № 49-125 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына кертергә (Шахмай авыл җирлеге Советы карарлары редакциясендә 13.10.2015 № 2-7; 24.02.2016 № 11-25; 30.11.2016 № 21-48; 18.04.2017 № 26-63; 15.12.2017 № 36-86; 29.05.2018 № 40-95; 15.12.2018 № 47-115; 11.07.2019 № 52-129; 15.06.2020 № 63-153; 31.05.2021 № 13-30; 28.12.2021 № 17-57; 12.07.2022 № 25-80; 21.03.2023 № 33-107; 17.04.2024 № 44-140; 2.12.2024 № 49-152;) (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. Уставның 1 статьясындагы 2 пунктында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «, кыскартылган исеме «Шахмай АҖ» сүзләрен өстәргә»;

1.2. Уставның 30 статьясы 7.6 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Уставның 34 статьясындагы 1 өлешенең 25 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. Уставның 79 статьясындагы 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Советы карары нигезендә җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда төзелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, Җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 05-11844/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Н.М. Илалова